СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 344 от 29.04.2020
на № __от ________

# КАРАР

Саба муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы Регламентын раслау турында” 2005 елның 9 декабрендә кабул ителгән 31 номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында

Саба муниципаль районы советы утырышларын югары әзерлек режимы, гадәттән тыш хәл режимы, чикләү чаралары (карантин), гадәттән тыш яки хәрби хәлләр чорында үткәрү максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Саба муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы Регламентын раслау турында” (Саба муниципаль районы Советының 2009 елның 12 ноябрендәге 274 номерлы, 2014 елның 25 февралендәге 240 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән (алга таба текст буенча - Регламент) 2005 елның 9 декабрендә кабул ителгән 31 номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы Советы Регламентына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 3 статьяны түбәндәге эчтәлектәге 4 пункт белән тулыландырырга:

“4. Югары әзерлек режимы, гадәттән тыш хәл режимы, чикләү чаралары (карантин), гадәттән тыш яки хәрби хәлләр режимы чорында район Советы утырышлары дистанцион рәвештә, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәре чараларыннан яки видеоконференцэлемтә каналларыннан файдаланып, әлеге пунктта билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып үткәрелә ала.

Совет утырышында карарлар дистанцион рәвештә ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавыш бирү, сораулар бирүгә язылу, чыгышлар ясауга язылу утырышта катнашучы депутатларны сораштыру юлы белән үткәрелә (куллар күтәрү, Совет депутатлары тарафыннан утырыш башында дистанцион рәвештә билгеләнгән башка ысуллар кулланып үткәрелә ).

Чакырылучылар Совет утырышында элемтәнең мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрләреннән файдаланып, дистанцион рәвештә катнаша алалар.

Совет утырышын үткәргәндә утырыш беркетмәсе дистанцион рәвештә рәсмиләштерелә, бу беркетмә утырышта рәислек итүче тарафыннан имзалана. Совет утырышы беркетмәсенә дистанцион рәвештә утырышны үткәргәндә кулланыла торган программа чаралары турында белешмәләр, утырыш башлану һәм тәмамлану вакыты, шулай ук әлеге регламентта каралган башка мәгълүматлар кертелә. Беркетмәгә утырышның аудио - һәм видеоязмасы кушып бирелә.”.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р. Н. Минниханов